ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 26 ноябрендә
кабул ителде

## 1 статья

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 1999, № 8 (I өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 статьяның 2 пунктында “тискәре (зарарлы) табигый, антропоген һәм техноген күренешләр тәэсиреннән” сүзләрен “тискәре йогынтыдан” сүзләренә алмаштырырга;

2) 12 статьяның 6 пунктында “(зарарлы)” сүзен төшереп калдырырга;

3) 25 статьяда:
а) исемендә “бурычлары” сүзен “асылы” сүзенә алмаштырырга;
б) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“2. Җирләрне саклауның максатлары җирләрнең һәм туфракның пычрануын, ярлылануын, начарлануын, бозылуын, юк ителүен һәм җирләргә, туфракка башка тискәре йогынтыны булдырмый калудан һәм бетерүдән, шулай ук җирләрдән рациональ файдалануны, шул исәптән авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә туфракның уңдырышлылыгын торгызу һәм җирләрне яхшырту өчен тәэмин итүдән гыйбарәт.”;
в) 3 пунктның 2 пунктчасында “башка тискәре (зарарлы) йогынтылардан” сүзләрен “башка тискәре йогынтыдан” сүзләренә алмаштырырга;

4) 26 статьяның 1 пунктында “тискәре (зарарлы) хуҗалык эшчәнлеге йогынтыларыннан” сүзләрен “тискәре йогынтыдан” сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон 2015 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2014 елның 15 декабре
№ 123-ТРЗ